

Зубово-Поляна районындагы Горенка топ мәктәбе укучылары Кочетовка авылындагы мәчеттә экскурсиядә булдылар.
Мәктәп зур булмаса да, укучылары бу мәктәпне данлый. Бу буш сvзләр генә тvгел. Экскурсиядә катнашкан Горенка мәктәбенен 9 сыйныф укучысы Мамина Самира кvпторле конкурсларда, чараларда катнашып мактау яулаган; кvпбалалы Шлаевлар гаиләсендә тәрбияләнә торган 7 сыйныф укучысы Артур бар эшләрдә актив һәм унышлы, 4 сыйныф укучысы Шлаева Алиса да vзенен унганлыгы белән билгеле. Артур белән Алиса, милли кимемнәр киенеп, татар жырларын да жырларга яраталар. Кечкенә генә булса да тош кенә диләр мәктәпкәчә сенелкәшләре Аделина турында: ана бар нәрсә дә кызык. Алда санап киткән балалар барысы да зур теләк белән мәчеткә сәфәр кылалар. Алдан ук кайда баруларын белеп, бик тә әзерләнәләр, фото да шул турыда сойли.
Экскурсиянен максаты: мәдәният аша балаларга рухи-әхлакый тәрбия бирv. Үз тобәгебезнен тарихын, ата-бабаларыбызнын конкvрешен һәм нигезләрен белеп кенә vз Ватаныбызга мәхәббәт турында сойләргә момкин. Бу эшкә кvп коч кертә Зубово-Поляна районы Горенка мәктәбе директоры Светлана Филипповна Ромайкина, урынбасары - Анна Ивановна Кемайкина, укытучылары - Галина Ринат кызы Утимишева, Людмила Петровна Ромайкина, Алексей Михайлович Кемайкин, Нина Николаевна Телякова, Людмила Фёдоровна Комендантова һәм башкалар.
Максатны тормышка ашырып, Горенка авылы имамы Вахит Хәйдәр улы Немишев балалар белән кызыклы әнгәмә vткәргән. Баланын кvпмилләтле жәмгыятьтә унышлы vсvе очен яшьтәшләре һәм олкәннәр белән аралаша белv кирәк; бу эштә безгә торле милләт кешеләренен рухи-әхлакый кыйммәтләре турындагы белемнәр ярдәм итә. Мәчеткә экскурсия вакытында элеге мәсьәләләрне яктыртып, мисаллар ярдәмендә имам Вахит Хәйдәр улы балаларга житкергән.
Мәчеткә якынлашу белән башта бинасы халыкны каршы ала, аннары бинанын эчендәге матурлык. Экскурсия вакытында укучылар мәчет эче бизәлеше сәнгать олеше булган халык мәдәнияте белән танышалар. Биредәге һәрбер әйбернен vз урыны һәм vз мәгънәсе булуына инаналар. Тагы имам белән әнгәмәдән балалар Россия тарихынын бер олеше булган мәчетнен тозелv тарихы турында да сойли. Әби-бабайларыбыздан калган мирас ул. Мирас... Ул буыннан-буынга кvчеп килә торган байлык. Йола, гореф-гадәт һәм бәйрәмнәребез безнен рухи мирасыбыз, байлыгыбыз. Матди байлык ул бетә торган вакытлы нәрсә, ә рухи байлык, акыл коче белән хасил булган доньяга караш, кешеләрнен могалләмәсе, гореф-гадәте - мәнгелек.
Укучылар бик кvп сораулар бирделәр, аларга барысы да кызык булды. Хәтта ни очен мәчеткә кергәндә аяк киемен салырга кирәклеге соравына жавап алалар һәм моселман изге урыннарына бару кагыйдәләре белән дә танышалар.
Экскурсия танып белv ягыннан кызыклы һәм бай эчтәлекле була.

**Наилә НАСЫРОВА**